

«Быел җәй безнен районда узачак Ботенроссия авыл Сабан туенда «Этник авыл» эшләячәк, анда татар хатын-кызларынын борынгы кием-салым әйбер-ләре тәкъдим ителәчәк. «Алмаз» үзәгенен милли мәдәният бүлеге модире Альфия Асыйм кызы Максимова, архив материаллары буенча торгызылган костюм да шунда булачак, дип сойләде. Сабантуйда катнашучыларга, тарихи дореслек буенча, татар-мишәр гардеробынын предметлары тәкъдим ителер», - дип яза Ләмберә районы «Призыв» газетасы. Искәртеп алыйк: 2013 елда ук туган якны ойрәнүче Умида Яхина, «Призыв» газетасы хезмәттәшләре белән бергә, Ләмберә районы Пензятка авылында яшәүчеләр гаиләсендә борынгы күлмәккә тап булган. Бу күлмәк Нәгимә Гаязетдин кызы Кадикинанын булган.       Гадәттән тыш тарихи һәм үзенчәлекле кием дип шул чакта традицион татар костюмы турындагы заманча күзаллауларга туры килми кебек тоелган. Ә чынлыкта исә, әлеге табыш татар-мишәрләренен тарихи киемнәре үзенчәлекле икәнен тагы бер тапкыр дәлилли. Нягимә апага борынгы күлмәк әнисеннән мирас итеп калган; ул аны бик кадерле һәм ин тантаналы очракларда гына кигән. Ачыклык кертәбез: Нәгимә Гаязетдин кызынын 1925 елда туганын исәпкә алсак, әнисе - XIX гасырда туган, шул вакыт күлмәк тегелгән булса, ана, якынча, 100-150 яшь булырга момкин.



